СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.07.2022 г.Зеленодольск № 182

«Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен, гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 19 сентябрендәге 243 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Су кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 2022 елның 8 июнендәге 23/1-12-2022 номерлы Татарстан транспорт прокуратурасы протестын карап, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. « Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен, гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2007 елның 19 сентябрендәге 243 номерлы карары преамбуласында «Татарстан Республикасының яңа төзелгән җирлекләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2005 елның 12 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2007 елның 19 сентябрендәге 243 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен, гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. «Гомуми нигезләмәләр» бүлегенең 1 пунктындагы «Татарстан Республикасының яңа төзелгән җирлекләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2005 елның 12 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2.II бүлекнең 1.5 пунктындагы дүртенче абзацы. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен төшереп калдырырга.

2.3.II бүлекнең 1.8 пунктының беренче абзацында. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре «Татарстан Республикасының яңа төзелгән җирлекләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2005 елның 12 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**